СОВЕТ САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.01.2019 с. Сарманово № 162

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Сарман районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында»гы 2016 елның 12 декабрендәге 55нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законына, 2018 елның 13 июлендәге 50-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында" Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында"гы Татарстан Республикасы законына һәм "Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексына (ТР ДС тарафыннан 2018 елның 21 июнендә кабул ителде) туры китерү максатында һәм Сарман муниципаль районы прокурорының Нигезләмәнең аерым пунктларына протестын караганнан соң, Сарман муниципаль районы Советы карар бирә:

1.Сарман муниципаль район Советының 2016 елның 12 декабрендәге 55 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә"гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3нче бүлекнең 3нче пунктындагы 2нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажы ике елдан да ким булмау яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча дүрт елдан да ким булмаган эш стажы;

муниципаль хезмәтнең баш вазифалары буенча - муниципаль хезмәт стажы бер елдан ким булмау яки белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча ике елдан ким булмаган эш стажы».

2) 3нче бүлекнең 4нче пунктында "өлкән" сүзен "әйдәп баручы, өлкән" сүзләре белән алыштырырга.

3) 3нче бүлекнең 5нче пунктына түбәндәге эчтәлекле 5.1 һәм 5.2нче пунктчалар өстәргә:

"5.1 Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясендә муниципаль хезмәт вазифасын биләү өчен кирәк булган белгечлеккә, хәзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре каралган булса, белгечлек һәм хәзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, әлеге стажга гражданинның (муниципаль хезмәткәрнең) тиешле белгечлек

һәм (яки) хәзерлек юнәлеше буенча белем алу турында һәм (яки) квалификация турында документ алганнан соң әлеге белгечлек һәм (яки) хәзерлек юнәлеше буенча эшләгән чорлары кертелә.

5.2. Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазифаи инструкциясе буенча белгечлек, хәзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре каралмаган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә элеге стажга гражданинның (муниципаль хезмәткәрнең) муниципаль хезмәтне биләү өчен кирәкле квалификация таләпләренә туры килешле дәрәҗәдә һөнәри белем алу турында документ алганнан соң эшләгән чорлары кертелә.

4) 9нчы бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2нче һәм 3нче пунктларны өстәргә:

“2. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, муниципаль берәмлектә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыгы яисә үзлекләре (ата-анасы, ире-хатыны, балалары, абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе, кияве-килене, шулай ук иренең(хатынының) ата-анасы, абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе, балалары) булган очракта гражданин муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларына билгеләнә алмый, муниципаль хезмәткәр контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын били алмый.

3. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатында, әлеге җирле үзидарә органының сайлап куелучы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында әлеге вазифаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.”

5) 10нчы бүлекнең 1нче пунктындагы 1нче пунктчасын үз көчен югалткан дип таныргa.

6) 10нчы бүлекнең 1нче пунктындагы 3нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3) шәхсән яки ышанычлылары аша эшмәкәрлек белән шөгыльләнү, коммерциячел оешма белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу (сәяси партия белән идарә итүдән тыш; түләүсез нигездә профсоюз органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайлап куела торган органы белән идарә итүдә катнашудан тыш; съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашудан тыш; бердәнбер башкарма орган сыйфатында яки муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән коллегиаль идарә органнары составына кереп, югарыда күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашудан тыш (сәяси партия һәм профсоюз органыннан, шул исәптән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайлап куела торган органыннан кала), муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючы вәкаләтләрен тормышка ашыру яки муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек үзе гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булган оешманың идарә итү органнарында, ревизия комиссияләрендә түләүсез нигездә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен яклаудан тыш; федераль законнарда каралган башка очраклардан тыш;»

7) Нигезләмәнең 10нчы бүлегендәге 4нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән гражданин, әгәр әлеге оешма белән муниципаль (административ) идарә итүнең аерым функцияләре муниципаль хезмәткәрнең вазифаи (хезмәт) бурычларына кергән булса, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе ризалыгы белән, муниципаль хезмәттән киткәннән соң ике ел дәвамында оешмада хезмәт килешүе шартларында вазифаларны биләп торырга һәм (яки) гражданлык-хокук килешүе (гражданлык-хокук килешүләре) нигезендә бу оешмада 1 ай дәвамында 100 мең сумнан артык күләмдә эшләр башкарырга (бу оешмага хезмәт күрсәтергә) хокуклы.

8) 16нчы бүлекнең 3нче пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

"Җирле администрация территориаль органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылган очракта, аңа авыл җирлегендә, шәһәр округында урнашкан авыл торак пунктларында җирле администрация вәкаләтләреренең бер өлешен гамәлгә ашыру йөкләнә, муниципаль берәмлектә конкурс комиссиясе төзү тәртибе әлеге авыл торак пунктларының һәрберсендә гражданнар җыенында күрсәтелгән кандидатураларны аның әгъзалары исәбенә кертүне күздә тотарга тиеш".

9) 20нче бүлекнең 3нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вазифаи оклад күләме, шулай ук айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләме һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы чыгарган муниципаль хокукый актлар белән билгеләнә. Муниципаль хезмәткәргә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен вазыйфаи окладка закон нигезендә айлык өстәмә билгеләнә».

10) 23нче бүлекнең 1нче пунктының 1нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләгәндә муниципаль хезмәт стажына (гомуми озынлыгы) даими нигездә (штат нигезендә) эшләгән (урын биләгән) чоры кертелә:

11) Түбәндәге эчтәлектәге 25.1нче бүлекне өстәргә:

«25.1 Чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу һәм коррупциягә каршы көрәш максатында билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен җавапка тарту

1.Чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу буенча таләпләрне һәм коррупциягә каршы көрәш максатында "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен муниципаль хезмәткәргә " Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»Федераль законның 27 статьясында каралган түләтүләр салына.

2. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законының 14.1 һәм 15нче статьяларында каралган хокук бозулар ясалган очракларда, ышанычны югалту белән бәйле рәвештә, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәттән азат ителергә тиеш.

3. «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законының 14.1, 15 һәм 27нче статьяларында каралган түләтүләр Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый актларында һәм (яисә) муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә

1) коорупция һәм башка торле хокук бозуларга профилактика буенча муниципаль органның кадрлар хезмәте тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсе турында доклад;

2) тикшерүләр нәтиҗәсе турында доклад комиссиягә җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе тәгъдиме;

2.1) коорупция һәм башка торле хокук бозуларга профилактика буенча муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлегенең коррупция белән бәйле хокук бозу булуы турында фактларга нигезләнгән доклады һәм муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы бары тик аның ризалыгы белән һәм коррупция белән бәйле хокук бозу фактын тануы (ышанычны югалту белән бәйле рәвештә эштән азат итү формасында җавапка тартуны кулланудан тыш)

3) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмасы;

4) башка материаллар нигезендә

эшкә яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан кулланыла,

4.«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль законының 14.1, 15 һәм 27нче статьяларында каралган җавапка тарту төрләрен кулланганда, муниципаль хезмәткәр тарафыннан кылынган коррупциячел хокук бозу характеры, аның авырлыгы, ул вакыттагы хәлләр, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәткәрләргә карата башка чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча таләпләрне һәм коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәүве, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең моңа кадәр үз вазыйфаларын башкару нәтиҗәләре исәпкә алына.

5.Муниципаль хезмәткәр тарафыннан коррупциячел хокук бозу кылынган очракта муниципаль хезмәткәре җавапка тарту турындагы актта җавапка тартуның нигезе итеп 25.1нче бүлекнең 1 яки 2нче кисәге күрсәтелә.

6.Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 статьяларында каралган түләтүләр «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары һәм (яисә) муниципаль норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда кулланыла.

7.Муниципаль хезмәткәргә ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендәге җавапка тартуны куллану турындагы мәгълүматлар муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт узган җирле үзидарә органы тарафыннан "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законының 15нче статьясы буенча ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән затлар реестрына кертелә.

2.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Советының Законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы рәисе — Ф. М. Хөснуллин